Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгарчен авылҗирлеге составына керүче Күгәрчен авыл җирлегендә гражданнар җыены **КАРАРЫ**

19 ноябрь 2024 ел № 2

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Күгәрчен авыл җирлеге составына керүче авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең Күгәрчен авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, беренче группа инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз яшәүче пенсионерлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, (гомуми саны 30 проценттан артмаган очракта) һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?:

1. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

- торак пунктчикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су белән тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт территориясен төзекләндерү.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Күгәрчен авылы, Зәитовлар урамы, 1А йорт Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципальрайонының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күгәрчен авыл җирлеге башлыгы: А.Т.Сафин